**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 12 Закона Республики Татарстан «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
13 июля 2023 года

**Статья 1**

Внести в статью 12 Закона Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 11 (I часть); 2013, № 11 (I часть); 2014, № 1 – 2, № 12 (II часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2022, № 17 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1:
а) дополнить пунктами $3^1 – 3^3$ следующего содержания:
«$3^1$) граждане, проходящие (проходившие) военную службу в Вооруженных Силах Российской Федерации, граждане, находящиеся (находившиеся) на военной службе (службе) в войсках национальной гвардии Российской Федерации, в воинских формированиях и органах, указанных в пункте 6 статьи 1 Федерального закона от 31 мая 1996 года № 61-ФЗ «Об обороне», при условии их участия в специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области и (или) выполнения ими задач по отражению вооруженного вторжения на территорию Российской Федерации, в ходе вооруженной провокации на Государственной границе Российской Федерации и приграничных территориях субъектов Российской Федерации, прилегающих к районам проведения специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики,

Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области, находящиеся (находившиеся) на указанных территориях служащие (работники) правоохранительных органов Российской Федерации, граждане, выполняющие (выполнявшие) служебные и иные аналогичные функции на указанных территориях, а также члены семей указанных граждан;

$3^2$) граждане, призванные на военную службу по мобилизации в Вооруженные Силы Российской Федерации, граждане, заключившие контракт о добровольном содействии в выполнении задач, возложенных на Вооруженные Силы Российской Федерации, при условии их участия в специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области и (или) выполнения ими задач по отражению вооруженного вторжения на территорию Российской Федерации, в ходе вооруженной провокации на Государственной границе Российской Федерации и приграничных территориях субъектов Российской Федерации, прилегающих к районам проведения специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области, граждане, заключившие контракт (имевшие иные правоотношения) с организацией, содействующей выполнению задач, возложенных на Вооруженные Силы Российской Федерации, при условии их участия в специальной военной операции на указанных территориях, а также члены семей указанных граждан;

$3^3$) лица, принимавшие в соответствии с решениями органов государственной власти Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики участие в боевых действиях в составе Вооруженных Сил Донецкой Народной Республики, Народной милиции Луганской Народной Республики, воинских формирований и органов Донецкой Народной Республики и Луганской Народной Республики начиная с 11 мая 2014 года, а также члены семей указанных лиц;»;

б) пункты $8^3$ – $8^5$ признать утратившими силу;

2) в части 2:

а) пункт $10^2$ после слова «интересов» дополнить словом «детей-инвалидов,»;

б) дополнить пунктами 17 – 21 следующего содержания:

«17) обеспечение денежным довольствием военнослужащих и предоставление им отдельных выплат в соответствии с Федеральным законом от 7 ноября 2011 года № 306-ФЗ «О денежном довольствии военнослужащих и предоставлении им отдельных выплат»;

18) предоставление льгот, социальных гарантий и компенсаций лицам, указанным в пунктах $3^1$ и $3^2$ части 1 настоящей статьи;

19) предоставление льгот, социальных гарантий и компенсаций лицам, указанным в пункте $3^3$ части 1 настоящей статьи;

20) признание гражданина из числа лиц, указанных в пунктах $3^1$ и $3^2$ части 1 настоящей статьи (за исключением членов их семей), безвестно отсутствующим;

21) объявление гражданина из числа лиц, указанных в пунктах $3^1$ и $3^2$ части 1 настоящей статьи (за исключением членов их семей), умершим.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Действие положений пунктов $3^1$ и $3^2$ части 1, пунктов 17, 18, 20 и 21 части 2 статьи 12 Закона Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» распространяется на правоотношения, возникшие с 24 февраля 2022 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 июля 2023 года
№ 68-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ – $3^3$ пунктлар өстәргә:
«$3^1$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче (үткән) гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, күрсәтелгән территорияләрдә булучы (булган) Россия Федерациясе хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшләүчеләре), күрсәтелгән территорияләрдә хезмәт функцияләре һәм башка шундый ук

функцияләр башкаручы (башкарган) гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

$3^{2}$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм күрсәтүче оешма белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) гражданнар, аларның күрсәтелгән территорияләрдә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

$3^{3}$) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә 2014 елның 11 маеннан башлап Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби гамәлләрдә катнашкан затлар, шулай ук әлеге затларның гаилә әгъзалары;»;

б) $8^{3}$ – $8^{5}$ пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 өлештә:

а) $10^{2}$ пунктта «ятим балаларның» сүзләрен «инвалид балаларның, ятим балаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 – 21 пунктлар өстәргә:

«17) хәрби хезмәткәрләрне акчалата тәэмин итү һәм «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата тәэминаты һәм аларга аерым түләүләр бирү турында» 2011 елның 7 ноябрендәге 306-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга аерым түләүләр бирүне тәэмин итү;

18) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^{1}$ һәм $3^{2}$ пунктларында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

19) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^{3}$ пунктында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

20) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^{1}$ һәм $3^{2}$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны хәбәрсез югалган дип тану;

21) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^{1}$ һәм $3^{2}$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны үлгән дип игълан итү.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең $3^1$ һәм $3^2$ пунктлары, 2 өлешенең 17, 18, 20 һәм 21 пунктлары нигезләмәләренең гамәли көче 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 68-ТРЗ